ГЛАВА КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-19; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“21 ” октябрь 2020 ел. — № 4

Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Пойкино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Келәүш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-46 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Пойкино авылы клубы мөдире Герасимова Людмила Николаевнаны Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Пойкино торак пунктында 2020 елның 10 ноябрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы: Б.В.Иванов